ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**26.01.2022**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 130**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23.5 статьясындагы 5 өлеше, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, гамәлдәге законнарга туры китерү, Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге карарларының үз көчләрен югалтуын танырга:

«Зеленодольск муниципаль районы территориясендә күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү буенча Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының административ регламентын раслау турында» 2017 елның 27 сентябрендәге 2462 номерлы;

«Зеленодольск муниципаль районы территориясендә күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү буенча Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының административ регламентын раслау турында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 27 сентябрендәге 2462 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 16 октябрендәге 2181 номерлы;

«Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 27 сентябрендәге 2462 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы территориясендә күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен башкаруның, шулай ук Зеленодольск муниципаль районы территориясендә күпфатирлы йортлар төзүгә бәйле торак - төзелеш кооперативлары эшчәнлеге административ регламентына үзгәрешләр кертү турында (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 16 октябрендәге 2181 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән)» 2020 елның 20 мартындагы 574 номерлы;

«Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 27 сентябрендәге 2462 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы территориясендә күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү буенча Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 20 мартындагы 574 номерлы, 2019 елның 16 октябрендәге 2181 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән)» 2020 елның 14 декабрендәге 2436 номерлы;

«Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 27 сентябрендәге 2462 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы территориясендә күпфатирлы йортларны төзү белән бәйле, күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү буенча Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2021елның 10 октябрендәге 2208 номерлы;

«Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 27 сентябрендәге 2462 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы территориясендә күпфатирлы йортларны төзү белән бәйле, күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү буенча Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 7 октябрендәге 2457 номерлы.

2. Зеленодольск муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Р. Ганиев